| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 24.11.2021 | Казан ш. | № 368-30/тко-2021 |

Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №11-32/тко карары белән билгеләнгән озак сроклы чик дәрәҗә тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы чик тарифларны үзгәртү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга «Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 № 11-32/тко карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 553-13/тко-2020 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 11-32/тко карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2021 № 368-30/тко-2021 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

## 2020-2022 елларга шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2022 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Кайбыч муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы* | 73,64 | 117,72 | 117,72 | 128,12 | 124,58 | 124,58 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 11-32/тко карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2021 № 368-30/тко-2021карары
редакциясендә) 2 нче кушымта

Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен 2020-2022 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче оешма исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2020 | 3360,47 | 1 | 0 | 0,05 |
| | | 2021 | 3446,63 | 1 | 0 | 0,05 |
| | | 2022 | 4424,61 | 1 | 0 | 0,05 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге